СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2023 г. Заинск № 139

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 136 номерлы «Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының 2013 елның 22 ноябрендәге 136 номерлы «Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» карарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 18.03.2015 № 196, 11.05.2018 № 116, 14.10.2019 № 164, 09.07.2021 № 57) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. 8 нче бүлекнең 48 нче абзацында " шәһәр бюджетын тулыландырырга" сүзләреннән соң "(бюджетның бердәм счетындагы акча калдыкларын идарә итү буенча операциялардән, бердәм салым түләүенә бәйле операцияләрдән, мәҗбүри түләүләргә карата Евразия икътисади берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнары белән каралган аванс түләүгә бәйле операцияләрдән, Евразия икътисади берлеге хокукы һәм Россия Федерациясенең таможня көйләве турындагы законнары белән каралган акчалата залогка бәйле операцияләрдән тыш)" сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 17 бүлекнең 2 пунктының 2 абзацында "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен "Татарстан Республикасы Рәисе" сүзләре белән алыштырырга";

1.3. 37 нче бүлекнең 2 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган бюджет үтәлеше турында еллык хисап белән бер үк вакытта бюджет үтәлешен һәм бюджет хисаплылыгын анализлауны һәм муниципаль биремнең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләрен куллануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләрне, бюджет үтәлеше турында карар проекты, тиешле бюджет үтәлеше турында башка бюджет хисабы, башка документлар.»

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Совет рәисе** **Р.Г.Кәримов**